# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Актүбә ш.т.п. № 2 «26» октябрь 2024 ел

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә эгъзаларыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән, шулай ук 2 теркем инвалидлар өчен 400 сум күләмендә билгеләп, үзсалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә коелар урнаштырып, су белән тәэмин итү линияләрен капиталь ремонтлау, урамнарга: Каенлы, Радужная, Шатлык).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес: http://aznakayevo.tatarstan.ru буенча урнаштырырга, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районының
«Актүбә шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.Л. Севостьянов